ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27»июнь 2019 ел. № 256

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
яшьләр сәясәте учреждениеләре
хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү
шартлары турында
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыныц 2018 ел 14 августыннан 665 номерлы "Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында" карары белән расланган, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 21 июненнән 505 номерлы "Яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында" Карарын тормышка ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы яшьләр сәясәте учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 августыннан 392 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы яшьләр сәясәте учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::
V кисәктә:
2.4 пунктның алтынчы абзацында «26,5» саннарын "41,00" санына алмаштырырга;
6 таблицаны түбәндәге редакциядә бирергә:

6нчы таблица

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләүләр күләме

| Профессиональ квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре | ___ | 41,0 |

| | | |
|---|---|---|
| вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | беренче | 41,0 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | беренче-дүртенче | 41,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының профессиональ квалификация төркеме | беренче | 46,0 |
| | икенче | 49,0 |

4.4 пунктның алтынчы абзацында «26,5» саннарын “41,00” санына алмаштырырга;
11 таблицаны түбәндәге редакциядә бирергә:

11 нче таблица

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләүләр күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Вазыйфа атамасы | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|
| «Ярдәмче составның техник башкаручылары һәм артистлары вазифалары» профессиональ квалификация төркеме | барлык вазыйфалар | 41,0 |
| “Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары” һөнәри квалификация төркеме | аккомпаниатор, костюмер мөдире | 49,0 |
| | түгәрәк, һәвәскәрләр берләшмәсе, кызыксыну клубы җитәкчесе, культорганизатор | 61,0 |
| “Әйдәп баручы звеноның мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары” һөнәри квалификация төркеме | барлык вазыйфалар | 49,0 |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфасы» һөнәри квалификация төркеме | барлык вазыйфалар | 49,0 |

2. ““Ровесник” яшүсмерләр клубы” муниципаль бюджет учреждениесе (О. Ю. Афанасьева), «Яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе (М. Ф. Шахмин), «”Форпост” җәмәгать тәртибен саклау буенча иҗтимагый берләшмәләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе (Мөхәммәтҗанова И. С.) җитәкчеләренә:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының яшьләр сәясәте

учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартларын билгеләүче кумәк шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. 3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2018 елның 10 маеннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.С. Авдеев**